КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 7 октябрь г.Казань № 809

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 9 август, 553 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 9 август, 553 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 3 октябрь, 1220 нче; 2024 ел, 5 февраль, 55 нче; 2024 ел, 11 июнь, 418 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына, аны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2013 ел, 9 август, 553 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 7 октябрь, 809 нчы
карары белән расланды)

## «Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы

## «Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру өлкәсендә стратегик өстенлекләр

### I. Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә хәзерге хәлне бәяләү

«Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы (алга таба – дәүләт программасы) халыкны эш белән тәэмин итү, эшмәкәрлекне һәм үзмәшгульлекне үстерү өчен шартлар тудыруга, Татарстан Республикасы икътисадының эшче көченә ихтыяҗын тәэмин итүдә булышлык күрсәтүгә, эшче көченең сыйфатын яхшыртуга, эшсезлек дәрәҗәсен киметүгә юнәлдерелде.

Дәүләт программасы узган еллардагы халыкны эш белән тәэмин итү буенча республика программаларын тормышка ашыру нәтиҗәләрен, шулай ук 2009 елдан бирле республика территориясендә төбәк программалары кысаларында хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелеп гамәлгә ашырыла торган өстәмә чараларны исәпкә ала.

2014 – 2024 еллар чорында хезмәт базарындагы вәзгыятьне тотрыкландыру буенча дәүләт программасын гамәлгә ашыру барышында кабул ителгән чаралар Татарстан Республикасында халыкның эш белән тәэмин ителеше белән бәйле хәлгә сизелерлек уңай йогынты ясады.

2025 ел башына Татарстан Республикасы халкының гомуми саны 4,0 млн.кеше, шул исәптән 2,3 млн эшкә яраклы яшьтәге граждан тәшкил итте.

2014 елдан бирле Татарстан Республикасы икътисадында эшләүче гражданнар саны 1 961,4 мең кешедән (2014 елга уртача) 2 036,3 мең кешегә кадәр (2024 елга уртача) артты. Халыкара хезмәт оешмасы методологиясе буенча исәпләнгән эшсезләр саны 80,7 мең кешедән (2014 елга уртача) 38,3 мең кешегә кадәр (2024 елга уртача) кимеде.

2024 ел башына Татарстан Республикасы хезмәт базары халыкның эш белән югары дәрәҗәдә тәэмин ителеше һәм эшсезлекнең түбән дәрәҗәдә булуы белән характерланды.

Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән эшсез гражданнар саны 2025 елның 1 гыйнварына 3 235 кеше, теркәлә торган эшсезлек дәрәҗәсе – республиканың эшче көче саныннан 0,16 процент тәшкил итте.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында эшсезлек нигездә структур характерга ия һәм җитештерүдә эшче көчкә ихтыяҗ структурасына йогынты ясый торган технологик үзгәрешләр белән бәйле рәвештә, халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшсез гражданнарга һөнәри белем бирү һәм өстәмә белем бирү программалары өлешендә зурлар яшендәге гражданнарга өзлексез белем бирү эшсезлек үсешен тоткарлауның, гражданнарның нәтиҗәле мәшгульлеген тәэмин итүнең, аларның конкурентлык сәләтен һәм хезмәт мобильлеген арттыруның иң нәтиҗәле инструменты булып тора.

Соңгы елларда хезмәт базарының уңай үзгәрешләренә эшче көчкә даими ихтыяҗ булу керә. Хезмәт миграциясе икътисадның мөһим элементларыннан берсе, хезмәт базарының нәтиҗәле коралы булып тора. Миграция процесслары эш бирүчеләр тарафыннан билгеле бер вакыт аралыгына аерым эш төрләрен башкаруга билгеләнгән вакантлы эш урыннарын биләү өчен төп чыганак булып кала.

2025 елның 1 гыйнварына эш бирүчеләр тарафыннан игълан ителгән вакансияләр саны 46,4 мең берәмлек тәшкил итте. Хезмәт базарындагы киеренкелек коэффициенты вакансиягә 0,07 кеше тәшкил итә, ягъни бер эшсез кешегә шартлы рәвештә 14тән артык вакансия тәкъдим итәргә була (2025 елның 1 гыйнварына теркәлгән эшсезләр саны – 3,2 мең кеше, теркәлгән эшсезлек дәрәҗәсе 0,16 процент тәшкил итте).

Эшче көченә, күпчелек очракта югары квалификацияле эшчеләргә ихтыяҗ эшче көченә булган тәкъдимне тормышка ашыру өчен җитәрлек түгел, һәм аны канәгатьләндерү, элеккечә, эшче көченә ихтыяҗ белән тәкъдименең структур туры килмәве аркасында тоткарланачак.

Эшче көченә ихтыяҗ һәм тәкъдимнең һөнәри-квалификация ягыннан, шулай ук территориаль туры килмәвенә бәйле рәвештә республиканың кайбер оешмалары эшче көченә, бигрәк тә кайбер һөнәрләр буенча югары квалификацияле кадрларга һәм квалификациясез хезмәт эшчеләренә кытлык кичерүен дәвам итә. Бу хезмәт базарын җайга салу өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру чараларын (хезмәт ресурсларының территориаль мобильлеген арттыру һәм чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү чараларын) планлаштыру зарурлыгын билгели.

Татарстан Республикасы Россия Федерациясенең миграция җәлеп итүче төбәге булып тора.

2025 елның 1 гыйнварына карата Татарстан Республикасы территориясендә тору урыны буенча гамәлдәге миграция исәбендә 81 538 чит ил гражданы фактта тора, 21 801 чит ил гражданы вакытлыча яшәү өчен рөхсәтнамә һәм яшәү төре нигезендә яши. Шулай итеп, республикада 103 339 чит ил гражданы һәм гражданлыгы булмаган затлар бар.

Чит ил гражданнарының төп килү максатларыннан берсе – эшкә урнашу мөмкинлеге.

2024 елда 146,2 мең чит ил гражданы эшкә урнашу максаты белән республикага

килү турында белдерде. 111,4 мең чит ил гражданының, шул исәптән хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру максаты белән килгән 79,4 мең кешенең яшәү (миграция исәбенә куелу) вакыты озайтылды.

Кеше капиталын формалаштыручы факторларның берсе – хезмәтнең куркынычсыз шартларын тәэмин итү өчен шартлар булдыру. Татарстан Республикасы – актив үсеш алган производство белән инвестицияләр җәлеп итүче төбәк, шуңа бәйле рәвештә хезмәтне саклау мәсьәләләре аерым актуальлек ала.

Хезмәтне саклау – хезмәт эшчәнлеге процессында гражданнарның тормышын һәм сәламәтлеген саклауның иң мөһим шарты. Хезмәтне саклау белән дәүләт идарәсе системасы хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга, хезмәт барышында кешенең иминлеген, сәламәтлеген һәм эшкә сәләтлелеген тәэмин итү буенча хокукый, социаль-икътисадый, оештыру-техник, санитария-гигиена, дәвалау-профилактика һәм башка чараларны гамәлгә ашыруга юнәлдерелде.

Имин хезмәт шартлары тудыру, имгәнүләрне булдырмау турыдан-туры мәгълүмат белән оештырлыган рәвештә тәэмин итүгә һәм хезмәтне саклауны пропагандалауга бәйле; ул кешеләрнең тормыш позициясенә, җитештерүдә гомерне һәм сәламәтлекне саклау белән бәйле төрле ситуацияләрдә аларның үз-үзләрен тотышына йогынты ясый торган эмоциональ халәт формалаштыру максатларында фән һәм техниканың соңгы казанышлары турындагы мәгълүматны, идеяләрне, мәгълүматларны таратуга юнәлдерелә.

## II. Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру өлкәсендә дәүләт сәясәте приоритетлары һәм максатлары тасвирламасы

Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләре:

1) гражданнарга тиешле эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда ярдәм күрсәтү;

2) эш эзләүдә авырлык кичерүче гражданнарны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү чараларын гамәлгә ашыру;

3) Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында һәм муниципаль хокукый актларда каралган тәртиптә гамәлдәге эш урыннарын саклап калучы һәм яңа эш урыннары булдыручы эш бирүчеләрне бүләкләү;

4) гражданнарның эшмәкәрлек инициативасына булышлык күрсәтү;

5) һөнәри ориентацияне, һөнәри белем бирүне һәм өстәмә һөнәри белем бирүне кертеп, гражданнарга һөнәри үсештә булышлык күрсәтү;

6) хезмәт ресурслары мобильлегенә ярдәм күрсәтү;

7) массакүләм һәм озак вакытлы (бер елдан артык) эшсезлекне кисәтү;

8) гражданнарга һәм эш бирүчеләргә дәүләт ярдәме чараларын, эшсез гражданнарга һәм гражданнарның башка категорияләренә социаль түләүләрне кертеп, халыкның эш белән тәэмин ителеше өлкәсендә дәүләт гарантияләрен билгеләү;

9) гражданнар һәм эш бирүчеләр өчен дәүләт ярдәме чараларыннан файдалану

мөмкинлеген һәм аларның адреслы булуын тәэмин итү;

10) халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте эшчәнлеген тәэмин итү һәм үстерү.

Дәүләт программасы приоритетлары Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәр һәм 2036 елга перспективага Россия Федерациясенең илкүләм үсеш максатлары турында» 2024 елның 7 маендагы 309 номерлы Указына, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган 2030 елга кадәр һәм 2036 елга кадәр перспективага Россия Федерациясенең илкүләм үсеш максатларына ирешү буенча бердәм планына, шулай ук «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясенә (алга таба – Стратегия-2030) туры килә.

Стратегия-2030 нигезендә Татарстан Республикасы 2030 елга кеше капиталын үстерү сыйфаты буенча Россия Федерациясендә лидер булырга тиеш. Балансслы хезмәт базары, халыкны эш белән тәэмин итү буенча нәтиҗәле сәясәт республикада кеше капиталын үстерү һәм тотып калу өчен өстәмә шартлар тудыра. Җитештерүне модернизацияләү, яңа технологияләргә күчү, яңа югары җитештерүчән эш урыннары булдыру «сыйфатлы» эшче көчен, югары квалификацияле хезмәткәрләрне таләп итә.

Дәүләт программасының максаты – 2028 елга халыкның эш белән тәэмин ителү дәрәҗәсен 60 проценттан түбәнрәк төшүгә юл куймау.

## III. Стратегик өстенлекләр, илкүләм максатлары һәм Стратегия-2030 максатлары, Россия Федерациясе дәүләт программалары күрсәткечләре белән үзара бәйләнеш турында белешмәләр

Стратегия-2030 максатлары, бурычлары һәм приоритетлары Россия Федерациясенең илкүләм үсеш максатлары белән һәм шактый дәрәҗәдә Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясенең илкүләм иминлеге стратегиясе турында» 2021 елның 2 июлендәге 400 номерлы Указы белән расланган Россия Федерациясенең илкүләм иминлеге стратегиясендә билгеләнгән Россия Федерациясенең илкүләм иминлеген һәм тотрыклы үсешен тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтенең стратегик илкүләм өстенлекләре белән туры килә.

«Халыкны саклап калу, кешеләрнең сәламәтлеген ныгыту һәм иминлеген арттыру, гаиләгә ярдәм итү» дигән Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатында шул исәптән «2030 елга ярлылык дәрәҗәсен 7 проценттан түбәнрәк һәм 2036 елга 5 проценттан түбәнрәк, шул исәптән күпбалалы гаиләләрнең ярлылык дәрәҗәсен 2030 елга 12 процентка һәм 2036 елга 8 процентка кадәр киметү» күрсәткече карала, Стратегия-2030да «Үзгәрүчән хезмәт базары, хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру, мәшгульлеккә ярдәм итү һәм социаль яклау системалары нәтиҗәле мәшгульлекне тәэмин итә һәм кеше капиталына кертемнәрдән конкурентлы керемнәр ала» дигән максатка туры килә.

Максатка ирешүне характерлый торган күрсәткечләрнең берсе – ул «Халыкара хезмәт оешмасы методологиясе буенча бер елга уртача эшсезлек дәрәҗәсе»

күрсәткече, шулай ук «Һөнәри белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларның гомуми санында укуны тәмамлаганнан соң беренче елда эшкә урнашкан һөнәри белем бирү оешмаларын тәмамлаучылар өлеше» һәм «Югары белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларның гомуми санында укуны тәмамлаганнан соң беренче елда эшкә урнашкан югары белем бирү оешмаларын тәмамлаучылар өлеше» күрсәткечләре.

## IV. Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүдә булышлык күрсәтү өлкәсендә һәм дәүләт идарәсе өлкәсендә дәүләт идарәсе бурычлары, аларны нәтиҗәле хәл итү ысуллары

Дәүләт программасы максатына ирешү өчен түбәндәге бурычлар хәл ителә:

эш эзләүче гражданнарны һәм эшсез гражданнарны, шул исәптән эшсез инвалидларны эшкә урнаштыруга ярдәм итү;

гражданнарга аларның мәшгульлегенә ярдәм итү максатларында квалификациясен күтәрү һәм өстәмә белем һәм күнекмәләр алу мөмкинлеге бирү;

халыкның эш белән тәэмин ителү дәрәҗәсенә ярдәм итү, дәүләт хезмәтләре күрсәтү процессларын цифрлаштыру максатларында цифрлы һәм платформалы чишелеәләрдән файдаланып, халыкны эш белән тәэмиин итү инфраструктурасын үстерү һәм оештыру һәм технологик инновацияләрне гамәлгә кертү;

эшсез гражданнарга аларның керемнәрен саклап калуга ярдәм итә торган социаль түләүләрне тәэмин итү;

хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, имин хезмәт культурасын арттыру.

«Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү кагыйдәләрен раслый торган Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары исемлеге

| Т/с | Документ тибы | Документ төре | Документ исеме | Реквизитлар | Эшләүче | Документ текстына гиперсылтама |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы | | | | | | |
| 1. | Субсидия бирү тәртибе | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары | Татарстан Республикасы территориясендә инвалидларны, шул исәптән махсус хәрби операциянең инвалид ветераннарын эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннары булдыруга эш бирүчеләр чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында | 2007 ел, 5 февраль, 32 нче | Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | https://pravo.tatarstan.ru/npa_kabmin/post/?npa_id=1566316 |
| 2. | Субсидия бирү тәртибе | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары | Татарстан Республикасы территориясендә оешмаларда, шул исәптән инвалидлар иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан төзелгән оешмаларда инвалидларның эш урыннарын саклап калуга бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында | 2015 ел, 23 гыйнвар, 35 нче | Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | https://pravo.tatarstan.ru/npa_kabmin/post/?npa_id=1544001 |

_________________________